29.08.2024 үткән
педагогик киңәшмәдә расланды
һәм балалар бакчасы мөдиренең
№ 38 -29.08.2024 боерыгы нигезендә
гамәлгә керде: беркетмә №1 - 29.08.2021
Балалар бакчасы мөдире: ............../ Мухаметзянова Ф.Х.

# Балык - Бистәсе муниципаль районы
# ББМБМБУ Котлы-Бүкәш
# “Дуслык” балалар бакчасының
# 2024-2025 нче уку елына укыту–тәрбия планы.

**с. Кутлу-Букаш**

**Визит карточкабыз.**

Татарстан Республикасы Балык - Бистәсе муниципаль районы Котлы-Бүкәш “Дуслык” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе Котлы-Бүкәш авылының нәкъ үзәгенә урнашкан. Ул 1988 елның 01 сентябреннән бирле һәр көн нәниләрнең шат авазларына күмелеп җанлы тормыш белән яши. Газ белән җылытыла. Мәйданы 1004 кв.метр. 60 балага исәпләнеп ике катлы типовой проект белән төзелгән бинада белем һәм тәрбия бирү эшчәнлеген оештыра. Бүгенге көндә балалар бакчасына 42 бала йөри, аларга 18 эшче хезмәт күрсәтә, шул исәптә 6 педагог. Мөдир, югары белемле; ике тәрбияче югары белемле, 1 нче категорияле, өч тәрбияче махсус урта белемле беренче категорияле. Балалар белән тәрбиячеләрдән тыш махсус урта белемле беренче категорияле1 физкультура инструкторы, рус теле тәрбиячесе. Өч махсус урта белемле кече тәрбияче балаларга хезмәт күрсәтә. Балалар бакчасында 3 төркем эшли, шуларның 1 се – нәниләр, 2 се мәктәпкәчә төркем.Эш режимы – 5 көн 10,5 сәгатьлек

**Тип:** мәктәпкәчә тәрбия учреждениясе

**Юридик адрес:** 422665,
Балык- бистәсе районы
Көтлы-Бүкәш авылы
Советлар урамы
Йорт номеры 39
**Телефон/факс**: 884361 31-5-36
E-mail:dou.ds.duslyk@tatar.ru

**Балалар бакчасы администрациясе**

Мөдир – Мөхәммәтҗанова Фәридә Хәмит кызы, югары белемле, эш стажы – 35 ел.
Исемлектәге балалар саны: 42 бала. Бакчада 3 төркем:
- кечкенәләр төркеме,
-2 кечкенәләр - уртанчылар төркеме,
-зурлар - мәктәпкә әзерлек төркеме,

Бакчада балаларга белем һәм тәрбия бирү өчен шартлар тудырылган, кирәкле әсбаплар һәм җиһазларбулдырылган. Җиһазларны урнаштыру куркынычсызлык һәм санитария – гигиена таләпләренә туры килә.

Кабул итү, уен, йокы, туалет, буфет бүлмәләре бар. Методик бүлмә, мөдир, музыкаль булмә.
Матур әдәбият, язучылар иҗаты почмаклары оештырылган, махсус үрнәкләр урнаштырылган. Барлык төркемнәрдә дә сенсорик тәрбия бирү почмагы җиһазландырылган, милли почмаклар булдырылган.

Табигать почмакларында һәр яшь төркеме өчен кирәк булган,программа таләп иткән бүлмә гөлләре һәмтабигатьне күзәтү календарьлары бар.

Акыл эшчәнлеген үстерү бөтен төр эшчәнлектә тормышка ашырыла, ләкин төп формасы шөгыльләрбулып санала.

Шөгыльләр барышында тәрбиячеләр күрсәтмә әсбаплар кулланалар, кече яшьтәге төркемнәрдә шөгыльләр уен рәвешендә үткәрелә. Шулай ук педагоглар халык авыз иҗатын киң кулланалар. Әзерләү һәм пешерү эшләре кухняда алып барыла. Кухня 1 нче этажда урнашкан, тиешле җиһазлар
белән тәэмин ителгән. Кер юу бүлмәсе, кер үтүкләү өчен урын билгеләнгән, чиста керләрне саклау өчен төркемнәрдә махсус шкафлар куелган.

Бакчага йөрүче балаларның 42 се татар, 42 бала рус теленә өйрәтелә. Бакчада белем һәм тәрбия бирү эшчәнлеге физик сәламәтләндерү юнәлешендә һәм экологик юнәлештә алып барыла.

Белем һәм тәрбия бирүдә куллана торган программалар Татарстан Республикасы Балык – Бистәсе муниципаль районы Котлы-Бүкәш “Дуслык” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белемучреждениесенең төп гомуми белем программасы;

**“Туганнан алып мәктәпкә кадәр” (мәктәпкәчә белемнең үрнәк төп гомумибелем программасы)**Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы. Мәскәү, 2015,авторлар: , Т.С.Комарова, Н.Е.Веракса, М.А.Васильева;

**Региональ программалар**
Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. - Казан, 2012, автор:Р.К. Шаехова;
«Куаныч» төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы –Казан, 2024, автор: Р.К.Шәехова ;
“Куанычым-багалмам” балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия, төзүче-авторы Кафия Закирова

**Парциаль программалар**
-“Туган телдә сөйләшәбез”.Методик кулланма Ф.Хазратова, З.Шәрәфетдинова,И.Хәбибуллина.Казан, 2013.
-“Изучаем русский язык”- С.М. Гаффарова, , Г.З. Гарафиева
-“Изучаем русский язык” рабочая тетрадь для детей (4-5 лет, 5-6 лет, 6-7 лет)- С.М.Гаффарова, ,Г.З. Гарафиева 2015г.

Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып Методик кулланма Р.К. ШәеховаМәктәпкәчәяшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып эш дәфтәре 1-2 кисәк;
Изобразительная деятельность
в детском саду Т.С. Комарова ( 4-5 лет. 5-6 лет, 6-7 лет) Мозаика – Синтез Москва 2015.
Формирвание элеентарных математических представлений (4-5 лет, 5-6 лет. 6-7 лет) Мозаика
– Синтез Москва 2016.

**Балалар бакчасының 2023-2024 нчы уку елындагы эшчәнлегенә анализ**Балалар бакчасында балаларның программа бурычларын үзләштерү мониторингы алып барыла.Елга ике тапкыр ( октябрь – май (апрель чыгарылыш) педагоглар диагностика үткәрә 2023-2024уку елында Котлы-Бүкәш балалар бакчасы **40 бала** белән комплектлаштырылды.
12 бала - 50% куп балалы гайләләр, 28 бала тулы түләде. 0 балага -20% , 7 балага - 50%, 7 балага -70% ата-аналар түләвеннән компенсация каралды һәм бу компенсация һәр балага да
вакытында кайтарылып барылды. 2023-2024 уку елында бакчага йөрүче балалар арасында авыр гаиләләр булмады.
Балалар бакчасы 4840 га. җирне биләп тимер койма белән әйләндереп алынган.
Территориядә үстерү өчен, шулай ук уен, физик тәрбия өчен мәйданчыклар бар.

Материаль – техник база канәгатьләнерлек хәлдә. Бакчага газ кертелгән, хезмәткәрләр көче белән газ котельнясына ремонт ясалды, азык-төлек склады төзекләндерелде. Комлыкка ком кайтартылды, торкемнэргэ керү юлы түшәлде.
Бакчада чәчәклекләр үстерелде.
2015 елдан Федераль дәүләт белем стандартлары гамәлгә керү сәбәпле Н.Е.Веракса, Т.С. Комарова, М.А.Васильева редакциялегендәге “От рождения до щколы ” программалары белән эшлибез. Матди-техник базаны җиһазлау буенча тәрбиячеләр авторлык пособиеләрен һәм уеннарын әзерләрләделәр. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә педагоглар тарафыннан эшләнгән комплекслы – тематик планлаштыруның барлык төрләре дә кулланыла, барлык белгечләрнең дә бердәммәгариф кинлегендә тыгыз багланышлары тормышка ашырыла. Белем бирү эшчәнлеге белем бирү өлкәләренең интеграциясе («социаль-коммуникатив үсеш», «танып-белү үсеше», «сөйләм үсеше», «сәнгать – эстетик үсеш», «физик үсеш») принцибын исәпкә алып, балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен (уен, коммуникатив эшчәнлекне, хезмәт эшчәнлеген, танып – белү эшчәнлеген, музыкаль-сәнгати эшчәнлекне, уку эшчәнлеген) оештыру процессында тормышка ашырыла. Балалар бакчасында эш, куелган бурычларга нигезләнеп алып барыла. Укыту – тәрбия процесын Сан ПИН кагыйдәләрен, таләпләрен саклану чараларын үтәп алып барылды. Төп бурыч Федераль дәүләт белем бирү стандартларына нигезләнеп белем бирү игътибар үзәгендә булды. Укыту – тәрбия эшендә инновацион технологияләр куллануга аеруча басым ясалды. Балалар белән шөгыльләрне кызыклы һәм мавыктыргыч итеп үткәрергә тырышабыз. Табигатьтә

булу, экскурсияләргә бару сабыйлар күңеленә аеруча хуш килә.
Бакчада балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту аларның физик һәм психик үсеше өчен шартлар тудыру өстендә эш дәвам итә.
Һәркөн иртәнге гимнастика, физик күнегүләр, спорт һәм халык уеннары ярдәмендә хәрәкәтне активлаштырып сәламәтлекне ныгыту өстендә эшлибез.
Ел дәвамында әти-әниләр белән тыгыз элемтәдә тордык. Даими рәвештә балаларның өйләрендә булдык, аларның уен почмаклары белән таныштык, гаилә членнары белән әңгәмәләр үткәрдек, киңәшләр бирдек. Эш планга нигезләнеп алып барыла. Уку елы дәвамында әти – әниләр белән берлектә системалы рәвештә бәйрәм иртәләре, күңел ачу кичәләре үткәрелде. Әти
әниләр җыелышлары түбәндәге темаларда үтте “Уку елына бурычлар һәм планнар”, "Гаилә белән берлектә тәрбия эшен оштыру”, “Бөтен нәрсә балачактан бирелгән тәрбиягә бәйле”. Ай саен күчмә папкаларда әти – әниләр өчен киңәшләр яңартылып торды.
Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга рухи – әхлакый тәрбия бирү уңаеннан уку елы дәвамында халык педагогикасына нигезләнеп әхлак тәрбиясенә дә зур урын бирелде. Халык педагогикасы нигезендә һәр халыкның үзенә генә хас тәрбия алымнары, гореф – гадәтләре, йолалары, тормыш
көнкүрешен оештыру, үз – үзен тоту рәвеше, әхлак нормалары, милли үзенчәлекләре ята. Бу күпкырлы тәрбия , шөгыльләрдә дәвамлы эшләү рәвешендә алып барылды. Халкыбызның онытылган гореф – гадәтләре, уеннары, җыр – биюләре, бәйрәмнәре өйрәтелде.
Милләтебезне, илебезне үстерү максаты белән күп кенә әңгәмәләр үтте, шигъри кичәләр, әдәби
- музыкаль композицияләр әзерләнде. Укыту – тәрбия процессының, рухи-әхлакый тәрбиянең югары дәрәҗәдә куелуы һәм системалы алып барылуы балаларда әдәплелек, мәрхәмәтлелек, инсафлылык тәрбияли, аларны үз –үзләрен тота белергә, тирә яктагы матурлыкны күрергә, өлкәннәргә, иптәшләренә ярдәмчел, игътибарлы булырга өйрәтә.
Бакчабызда методик ярдәмлек итеп, материал туплау һәм альбомнар, стендлар төзү эшләрен дәвам итәбез. “Мин яратам сине Татарстан”, “Идел буе халыклары” дип аталган стендлар ясадык. Туган ягым яшел бишек “Халкыбызның милли бизәкләре”, “Бәйрәмнәребез, йолаларыбыз” дигән альбомнар булдырылды.
Балаларга патриотк тәрбия бирү йөзеннән кабул итү бүлмәсенә түбәндәге темаларда стендлар ясалды :”Ут белән шаярырга ярамый”, “Терроризм”.
Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча тематик-перспектив план төзелде. Шул план нигезендә тәрбияче дәрес эшкәртмәләре булдырды. Шулай ук балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча табышмаклар, тизәйткечләр, такмаклар тупланды. Тәрбиячеләргә балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча ярдәмгә махсус әдәбият тупланган. Бакчабызда балалар белән күп төрле чаралар үткәрелә: “Белем бәйрәм”ендә катнаштык , “Сөмбеләне кем белә?” дип исемләнгән көзге бәйрәм ясадык, “Чыршы янында”, “Юлларда хәвеф булмасын”, Сәламәтлек көне”н, “Космонавтика” көнен билгеләп үттек .
Бөек Җиңү бәйрәме уңаеннан балалар белән бергә венок ясап һәйкәлгә куйдык. Үткәрелгән киңәшмәләрдә катнашып, тәҗрибә уртаклашабыз.
Безнең балалар бакчасында белем һәм тәрбия эше мәктәп белән тыгыз элемтәдә алып барыла. Коллективның тырышлыгы белән бакча тирәсендә җәй көне матур чәчәклекләр үстерелде, кыш көне кардан сыннар ясап куелды.
Балаларның туклану рационы ел дәвамында төрле ризыкларга бай булды, ел дәвамында яшелчә, җиләк-җимешләр белән тәэмин ителеп торды.
Киләчәктә максатыбыз тәрбия өлкәсендәге яңалыкларны тагын да өйрәнеп, эштә кулланма итеп алу. Балалар бакчасында йөрешне тагын да арттыру, авырып көн калдыруны киметү өстендә тагын да ныграк эшләргә. Балаларның тумыштан килгән сәләтләрен үстерүгә ныграк басым ясарга, аң дәрәҗәләрен төрле яклап үстерергә. Балаларның дус, үзара ярдәмләшә белүләрен игътибар үзәгендә тотарга. Сәламәт һәм белемле балалар тәрбияләү һәр тәрбиясенең изге бурычы.

**Эшчәнлекләр төре**

**Өзлексез акыл үсешен тәэмин итүгә шартлар**

1. Диагностика
2. Ата-аналарга консультация
3. Квалификация күтәрү курслар
4. Үстерешле уку.

**Иҗадилыкны үстерү**

1. Кул эшләре
2. Сынлы сәнгать
3. Музыка сәнгате

**Физкультура-сәламәтләнедерү эше**

1. Чыныктыру
2. Үз-үзеңә массаж, нокталы массаж
3. Гәүдәгә һәм яссытабанлыкка коррекцион эш
4. Көн дәвамында рациональ хәрәкәт активлыгы
5. Гимнастика төрләре: иртәнге, йокыдан соң, релаксакция, күзләргә, сулышюлларына
6. Физкультура шөгыльләре, уеннар, күңел ачу, саф һавага чыгу

**Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр турында мәгълүмат.**

Кадрлар белән тәэмин ителеш, аларны белем дәрәҗәсе:барлык
педагогик хезмәткәрләр – 10;
мөдир — 1
музыка җитәкчесе -0
физкультура тәрбиячесе -1
тәрбиячеләр -5
кече тәрбиячеләр-3

**Педагогларның белем дәрәҗәсе:**

| Уку елы | барлыгы | югары | махсус урта | Укый (ЮУЙ һ.б.) |
|---|---|---|---|---|
| 2022-2023 | 6 | 2 | 4 | - |
| 2023-2024 | 6 | 2 | 4 | - |
| 2024-2025 | 6 | 2 | 4 | - |

**Педагогларның эш стажы:**

| Уку елы | барлыгы | 20дән югары | 15-20 ел | 10-15 ел | 5-10 ел | 5 елга кадәр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2022-2023 | 6 | 3 | 3 | 0 | 0 | 0 |
| 2023-2024 | 6 | 4 | 2 | 0 | 0 | 0 |
| 2024-2025 | 6 | 4 | 2 | 0 | 0 | 0 |

**Квалификация категориясе:**

| Уку елы | барлыгы | югары | беренче | категориясез |
|---|---|---|---|---|
| 2022-2023 | 6 | - | 6 | - |
| 203-2024 | 6 | - | 6 | - |
| 2024-2025 | 6 | - | 6 | - |

**Бакча 60 урынга исәпләнгән. Бакчага йөрүче балалар саны:**

| Уку елы | Балалар саны | Төркемнәр саны | Шулардан ясле/бакча |
|---|---|---|---|
| 2022-2023 | 41 | 3 | 1 (12 бала) |
| 2023-2024 | 41 | 3 | 1 (14 бала) |
| 2024-2025 | 42 | 3 | 1 (19 бала) |

Бакчада 10.5 сәгатьлек эш көне белән 3 төркем эшли,
1 кечкенәләр төркеме – 19 бала
2 кечкенәләр -уртанчылар төркеме – 13 бала
Зурлар- мәктәпкә хәзерлек төркеме – 10 бала

**Балаларның милли составы:**

| № | Уку елы | Барлык балалар | Татарлар | Катнаш гаиләдән | Руслар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2022-2023 | 42 | 42 | 0 | 2 |
| 2 | 2023-2024 | 41 | 41 | 0 | 1 |
| 3 | 2024-2025 | 42 | 42 | 0 | 0 |

**Балаларның сәламәтлек төркеме.**

| № | Ел | 2022-2023 | 2023-2024 | 2024-2025 |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче группа | 15 | 12 | 16 |
| 2 | 2 нче группа | 25 | 17 | 22 |
| 3 | 3 нче группа | 2 | 2 | 3 |
| 4 | 4 нче группа | - | - | - |
| | **Барлык балалар саны** | **42** | **41** | **42** |

**Бер баланың авыру көннәр саны.**

| Төркемнәр | 2021-2022 | 2022-2023 | 2023-2024 |
|---|---|---|---|
| Бер баланың авыру көннәрсаны | 2,8 | 2,9 | 3 |

**Балаларның социаль паспорты**

| Категория | 2022-2023 | 2023-2024 | 2024-2025 |
|---|---|---|---|
| барлыгы | 42 | 41 | 42 |
| опекадагы балалар | 0 | 0 | 0 |
| инвалид балалар | 0 | 0 | 0 |
| «риск төркеме» балалары | 0 | 0 | 0 |
| күп балалы гаиләләр | 6 | 9 | 13 |
| малайлар | 21 | 27 | 30 |
| кызлар | 20 | 15 | 12 |

**Үстерешле акыл үсешен тәэмин итүгә шартлар**

Уенчыкларның, атрибутларның, башка материалларның үстерешле тирәлектә урнаштырылуы: белем бирү бүлеге, уен бүлеге, әдәби-зәвык бүлеге, милли тәрбия бүлеге, китап бүлеге, танып-белү, табигать бүлеге, иҗади эшчәнлек бүлеге.

Балалар бакчасында балаларны төрле яклап үстерү өчен шартлар тудырылган, җиһазлар белән җитәрлек күләмдә тәэмин ителгән һәм эффектлы кулланыла. Балалар бакчасының материаль-техник халәте ел саен яхшыртыла.
Табигать почмагы ел фасыллыры буенча; әти-әниләр почмаклары һәрдаим яңартылып тора. Балалар бакчасында тормышка ашырылучы гомуми методик тема: "Балаларны һәрьяклап тәрбияләүдә иҗади сәнгать эшчәнлеген үстерү", мәктәп алды әзерлеге.

Агымдагы елга ДОУ эшенең максаты:
бала тулысынча яшәү өчен уңай шартлар тудыру мәктәпкәчә балачак, аны исәпкә алып, төрле яклап үскән шәхес формалаштыру физик, психик үсеш, индивидуаль мөмкинлекләр һәм сәләтләр.

**Балалар бакчасының 2024– 2025 нче уку елына бурычлары:**

1. Педагогларның һәм ата-аналарның үзара хезмәттәшлеге системасын камилләштерүне дәвам итү, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дә ФГОС һәм ФОП кертергә.
2. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны әхлакый-патриотик тәрбияләү эшен дәвам итәргә Россия халыклары традицияләре һәм мәдәнияте белән танышуны дәвам итү;
2. Туган телдә белем бирү процессын, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга билингваль белем бирүне оештыру сыйфатын яхшыртырга.
3. 2024 елда МКДО нәтиҗәләрен анализлау нигезендә мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
4. Педагоглар, мәктәпкәчә белем бирү оешмасы һәм башлангыч гомуми белем дәвамчанлыгын тәэмин итү өчен, бердәм белем бирү мохитен эшен дәвам итү.

## I ПЕДАГОГИК ЭШНЕ ОЕШТЫРУ

### Педагогик киңәшмәләр август ае 2024 ел

**Тема:** 2024-2025 уку елына педагогик эшчәнлекне планлаштыру һәм оештыру»
**Максат:** Регламентлаштыручы норматив-хокукый документларны, Яңа уку елында балалар бакчасы эшчәнлеге, эшчәнлекне активлаштыру педагоглар фикер алышу процессында планлаштырыла торган эш перспективаларын раслау.
**Үткәрү вакыты:** 28 август, 2024 ел.

| № | Чаралар | Җаваплы |
|---|---|---|
| 1. | Алдагы киңәшмә карары үтәлеше | Бакча мөдире |
| 2. | Җәйге сәламәтләндерү эше нәтиҗәләре. | Мингазова Э.В. |
| 3. | Балалар бакчасынын, торкемнәрнен, кабинетларнын яна укуелынаәзерлегенә анализ | Бакча мөдире |
| 4. | ФДББС (ФОП) нигезендә тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеген оештырупланнарын тикшерү һәм раслау:<br>көндәлек режим,<br>белем бирү эшчәнлеге челтәре.<br>2023-2024 нче уку елына тәрбия-белем бирү эше планы еллык календарь график, комплекслы-тематик планнар,белгечләрнең еллыкэш планы юл картасы<br>«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм башкателләр» турындазаконны үтәү планы | |
| 5. | Педагоглар өчен консультацияләр "Педагогикларның компетенциясен арттыру мәсьәләләре буенча ФОП куллану | Бакча мөдире |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Аттестация стендын бизәү. Аттестация узу өчен педагоглар исемлеге. Сораулар буенча консультацияләр үткәрү, документлар кабул итү | Мөдир |
| 7 | Яңа килгән балаларны җайлаштыру (Адаптация) | Шагиева Л.Н. |

**ПЕДАГОГИК КИҢӘШМӘ № 2**
**Ноябрь ае 2024 ел**

**Тема: ФГОС таләпләреннән тайпылмыйча эшләү.**

**Максат**: педагогик эшчәнлекне оештырубарышында

балаларның ике дәүләт телен белүләренә ирешү; рус теле, татар теле шөгыльләрен үткәрүдә яңа методик эшчәнлекне оештыру.

| № | Чаралар | Җаваплы |
|---|---|---|
| 1. | Алдагы киңәшмә карары үтәлеше | Бакча мөдире. |
| 2. | Рус теле һәм татар теле шөгыльләрен үткәрүдә яңа методик эшчәнлекне оештыру. (чыгыш) | Тәрбиячеләр<br>Рус телчесе |
| 3. | Рус телен авыр үзләштерүче балалар белән индивидуаль эшне оештыру һәм контроль. | Мөдир<br>Рус телчесе |
| 4. | <u>Практик эш.</u><br>1.Ике теллелек буенча традицион булмаган кулланмага презентация. | Мингазова Э.В.<br>Тәрбиячеләр |
| 5 | Дидактик материалларга күргәзмә. | Тәрбиячеләр |

**III нче киңәшмә**
**Март ае 2025ел**

**Тема: “Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларның юл-транспорт травматизмын профилактикалау эшен оештыру"**

**Максат:** Балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтү эшендә тәрбиячеләр һәм белгечләр эшчәнлеген стимуллаштыру, үстерү, баету һәм активлаштыру;
Эш тәҗрибәсен мәктәпкәчә белем бирү педагоглары арасында тарату.

| № | Чаралар | Җаваплы |
|---|---|---|
| 1. | Алдагы киңәшмә карары үтәлеше | Бакча мөдире. |
| 2. | Балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү.<br>Иҗади эш тәҗрибәсе. | Шагиева Л.Н. |
| 3. | Юлда йөрү кагыйдәләрен өйрәнүгә карата дидактик уеннарга презентация. | Каримова З.Г |
| 4. | Тематик контроль нәтиҗәләре.<br>Тема: “Төркемдә юлда йөрү кагыйдәләрен өйрәнүнең торышы.” <u>Практик эш.</u> | Салимова Н.А. |
| 5 | Шөгыльләрдә балаларның кызыксыну күнекмәләрен формалаштыруда уен алымын куллану. (Эш тәҗрибәсеннән). | Сибгатуллина Г.Р. |
| 6 | Төрлеләр | Мөдир<br>Тәрбиячеләр |

**III нче киңәшмә**

**Май ае 2025 ел**

**Тема: «2024-2025 нче уку елы эшенә нәтиҗә»**

**Максат:** Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенә анализ

| № | Чаралар | җаваплы |
|---|---|---|
| 1. | Алдагы педагоглар киңәшмәсе карары үтәлеше | Бакча мөдире |
| 2. | Эш нәтиҗәләре :<br>А) Еллык эш планы бурычлары үтәлешенә анализ.<br>Б) «Безнең уңышлар»:<br>барлык төркемнәрдә эш нәтиҗәләре буенча отчет;<br>белгечләр эше планы үтәлеше буенча отчет;<br>уку елына сәламәтләндерү эшенә анализ;<br>балаларның мәктәпкә әзерлеге нәтиҗәләре<br>В) программаны үзләштерү мониторингы нәтиҗәләре | Бакча мөдире<br>Тәрбиячеләр,белгечләр мәктәпкә әзерлек төркеметәрбиячеләре мөдир |
| 3. | Милли тәрбия бирү буенча еллык эшчәнлеккә анализ. | мөдир |
| 4 | Чыныктыру-сәламәтләндерү эшчәнлегенә анализ, уку елында балаларның сәламәтлек торышына гомуми нәтиҗә. | Физкультура җитәкчесе |
| 5 | Җәйге сәламәтләндерү чорына бурычлар кабул итү һәм раслау. Эш планын раслау | Бакча мөдире, Физкультура җитәкчесе |

**Тәрбия процессын контрольдә тоту.**

| № | Эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| **Көндәлек контроль.** | | | |
| Максат: көндәлек чараларның сыйфатлы үтәлеше. | | | |
| 1. | Тормыш иминлеге нигезләренең үтәлеше. | Даими | Бакча мөдире. |
| 2. | Укыту-тәрбия процессы: әзерлек, оештыру, диагностикалар уздыру(сентябрь, май) | | |
| 3. | Балаларның үз-үзенә хезмәт күрсәтү күнекмәләре формалашуы. | | |
| 4. | Көндәлек режимда чыныктыру-сәламәтләндерү чараларының үтәлеше. | | |
| 5. | Балаларның бакчага йөреше. | | |
| 6. | Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтүнең үтәлеше. | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Периодик контроль.**<br>Максат: балалар белән эшчәнлекне өйрәнү һәм анынәтиҗәлелеген билгеләү. | | | |
| 1. | Тәрбияче ярдәмчесенең эшчәнлеге. | Ай саен | Бакча мөдире |
| 2. | Туклану нормаларының үтәлеше. | Ай саен | Бакча мөдире |
| 3. | Бала-көн планының үтәлеше. | Ай саен | Бакча мөдире |
| 4. | Тәрбияченең педсовет карарларын үтәве. | Ике айга бер | Бакча мөдире |
| 5. | Перспектив һәм көндәлек планнарның, документациянең торышы. | Кварталга бер | Бакча мөдире |
| **Тематик контроль.** | | | |
| 1, | Рус теле шөгыльләрендә балаларның грамоталы сөйләмнәрен формалаштыру эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге.<br>Максат: рус теле шөгыльләрендә балаларның грамматиккүнекмәләренең формалашу дәрәҗәсен билгеләү. | Март | Бакча мөдире. |

**Ата-аналар белән эш**

| | | |
|---|---|---|
| октябрь | Консультация “Әйләнә – тирә мөхит”. | Мөдир |
| | Күргәзмә:”Табигый манзара” | Тәрбияче |
| | “Сөмбелә”бәйрәме үткәрү. | Тәрбияче |
| | “Бергәләп өйрәник”темасына күчмә папка ясау | Тәрбияче |
| ноябрь | Аналар көненә карата бәйрәм иртәсе. | Тәрбияче |
| | Консультация “Сәламәт яшәү рәвеше”. (Халык медицинасыннан киңәшләр бирү) | Физик тәрбия житәкчесе. |
| декабрь | Төркем бүлмәсен, участокларны яңа ел бәйрәменә карата бизәүгә смотр. | Мөдир |
| | Яңа ел кичәсе. | Тәрбияче |
| | Төркемдә ата-аналар җыелышы.”Хәвефләргә юл куймыйк” | Тәрбияче |
| | Консультация “Балаларның сөйләм телен үстерүдә балалар бакчасының һәм гаиләнең хезмәттәшлеге”. | Тәрбияче |
| | Инструктаж үткәрү. | Мөдир |
| март | 8 март – халыкара хатын-кызлар көненә карата бәйрәм иртәсе. | Тәрбияче |
| | Котлау күчмә папкасы. | Тәрбияче |
| | Гомуми җыелыш. “Балабыз мәктәпкә әзерме”.<br>Инструктаж үткәрү. | Мөдир, тәрб. |
| | Консультация “Баланы үз–үзенә хезмәт күрсәтергә мөстәкыйльлеккә өйрәтү”. | Тәрбияче |
| апрель | Ата – аналарның тәрбия өлкәсендә белем дәрәҗәләрен арттыру: методик китаплар, газета –журналлар тәкъдим итү. | Тәрбияче |

| | | |
|---|---|---|
| | Балаларның кул эшләреннән күргәзмә “Без нәрсәләргә өйрәндек” (рәсемләү, кисеп ябыштыру, әвәләү, конструкцияләү алымнарын кулланып). | Тәрбияче |
| | Ачык ишекләр атналыгы.<br>- ачык шөгыльләр карау, буш вакытларны күзәтү. | Мөдир,тәрб. |
| май | Балаларны мәктәпкә озату кичәсен үткәрү. | Тәрбияче |
| | Ата-аналарны бакча территориясен төзекләндерү буенча өмәләргә чакыру. | Мөдир |
| | “Юлда да акыл кирәк”<br>Җәйге чорга инструктаж үткәрү. | Мөдир |
| | Җиңү парады. | Тәрбияче |
| | Сабантуй | Мөдир,тәрб. |

## Административ-хуҗалык эшләре.

| Үткәрү вакыты | Эчтәлек | Җаваплы |
|---|---|---|
| Август | 1.Гомуми җыелыш үткәрү.<br>Инструктаж үткәрү.<br>Участокларның чисталыгын, санитар хәлен тикшерү буенча рейд оештыру<br>Агымдагы ремонт эшләрен башкару: агарту, буяу, юу, җыештыру . | Бакча мөдире<br>Эшчеләр |
| Сентябрь | Белем көнендә катнашу<br>Төркемдәге җиһазларн маркировкалау.<br>3.Территориядә агачларны формалаштырып кисү, җирләрне казу.<br>4.Беренче ярдәм өчен кирәк – ярак һәм дарулар сатып алу.<br>5.“Тәрбиячеләр көне”н үткәрү | Мөдир,<br>тәрбияче<br>Тәрбияче<br>Эшчеләр |
| Октябрь | 1. ОТ буенча җаваплы кешене билгеләү, приказлар язу, инструкцияләрне яңарту<br>2.“Өлкәннәр көне”н үткәрү | Бакча мөдире |
| Ноябрь | 1.Хуҗалык әйберләренең тотылышын тикшерү<br>2.Бинаның яктылык белән тәэмин ителүен булдыру.<br>3.Кышка әзерлек: ишекне җылыту<br>4.“Аналар көне”н зурлап оештыру | Бакча мөдире<br>Эшчеләр |
| Декабрь | 1.Гомуми җыелыш.<br>-Инструктаж үткәрү.<br>2.Участокта кардан сыннар әвәләү буенча смотр уздыру<br>3.“Яңа ел” кичәләрен уздыру<br>4.Эшчеләрнең хезмәт кенәгәләрен, шәхсиэш папкаларын карап чыгу<br>5.Эшчеләр белән “Яңа ел” кичәсен үткәрү | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| Январь | Янгын куркынычсызлыгы буенчаприказларны яңарту | Бакча мөдире |

| | | |
|---|---|---|
| Февраль | 1. “Ватанны саклаучылар көне”нә багышлапәтиләр өчен спорт күңел ачу кичәләрен уздыру<br>2.Уенчыклар сатып алу<br>3.Үсентеләр өчен ящиклар, бакча эш коралларын әзерләү | Тәрбияче<br>Бакча мөдире |
| Март | Гаилә бәйрәмнәре уздыру<br>Табигать почмагының торышын карау, нәтиҗәясау.<br>Чәчәкләр чәчә башлау<br>Җәйге чорда башкарыласы ремонт эшләренең планын булдыру | Тәрбияче<br>Бакча мөдире |
| Апрель | Участокта эшләр:<br>1.Куак, агачларны кисү;<br>2Чәчәклекләр, түтәлләр ясау.<br>3.Г. Тукайга багышлап “Туган тел” бәйрәменуздыру<br>4.Уен мәйданчыгындагы җиһазларның төзеклеген тикшереп чыгу | Эшчеләр<br>Тәрбияче<br>Бакча мөдире |
| Май | 1.Участоктагы җиһазларны ремонтлау, буяу.<br>2.Чәчәкләр утырту.<br>3.Мәктәпкә озату бәйрәмен уздыру. 4.Чәчәкләрне тәрбияләп үстерү.<br>5. “1 июнь – Балаларны яклау көне”н уздыру.<br>6.“Сабантуй” бәйрәмен үткәрү. | Бакча мөдире<br>Эшчеләр<br>Тәрбияче |

**Мәктәп белән балалар бакчасының 2024-2025 нче уку елы өчен үзара эш планы.**

| № | Чаралар | Үткәрү вакыты | Кем җаваплы |
|---|---|---|---|
| <br>1. | Методик эш.<br>Башлангыч сыйныф укытучысы белән һәрвакыт элемтәдә тору. Аның үткәргән ачык дәресенә укырга керүче балаларны алып бару | Ел дәвамында | Тәрбияче |
| 2. | Рус теленнән ачык дәрескә чакыру | апрель | Тәрбияче |
| 1.<br>2.<br><br>3.<br><br>4.<br>5. | Экскурсияләр, максатлы прогулкалар<br>Мәктәпкә белем бәйрәменә бару.<br>Мәктәп музеена экскурсия.<br>Алтын көз табигатен күзәтү болынга экскурсия.<br>Яңа ел бәйрәменә кунакка бару<br>“Соңгы кыңгырау” бәйрәмендә катнашу | <br>Сентябрь<br><br>Октябрь<br><br><br>Декабрь<br>Май | <br>Мөдир<br>Тәрбияче<br><br>Тәрбияче<br><br><br>Тәрбияче |
| 1. | Шефлык эше.<br>Балаларга хезмәт тәрбиясе бирүдәмәктәпнең роле | Ел дәвамында | Тәрбияче |
| 2. | Бакчаны чәчәкләр белән тәэминитүдә булышу. | Май | Укытучы |
| 3. | “Бездән үрнәк алыгыз” темасына күргәзмә оештыру | Май | Мөдир |